| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.02.2020 г.Казань № 1

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 3 мартында 6539 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары

санын билгеләү турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1042» саннарын «1040» саннарына алмаштырырга;

1 нче кушымтада:

34 пунктның 2 графасында «Средволгаводхоз»ның су хуҗалыгы федераль дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләрен «Центррегионводхоз» су хуҗалыгы федераль дәүләт бюджет учреждениесенең «Средволгаводхоз» филиалы» сүзләренә алмаштырырга;

109 пунктның 2 графасында «3 нче Аксубай урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «3 нче Аксубай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

112 пунктның 2 графасында «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Лачын» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Лачын» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

145 пунктның 2 графасында «20нче балалар бакчасы муниципаль бюджет балалар мәгариф учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Ладушки» 20нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» сүзләренә алмаштырырга;

160 пунктның 2 графасында «Цеолиты Поволжья» ҖЧҖ» сүзләрен «Цеолиты Поволжья» ААҖ» сүзләренә алмаштырырга;

198 пунктның 2 графасында «Сетевая компания» ААҖ филиалы «Буа электр челтәрләре» сүзләреннән соң (Кама Тамагы районы электр челтәрләре) сүзләрен өстәргә;

202 пунктның 2 нче графасында «Сетевая компания» ААҖ филиалы «Алабуга электр челтәрләре» (Кама Тамагы районы электр челтәрләре)» сүзләрен «Сетевая компания» ААҖ филиалы «Алабуга электр челтәрләре» (Кукмара районы электр челтәрләре)» сүзләренә алмаштырырга;

211 пунктның 2 графасында «Лаеш район дәүләт берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләрен «Лаеш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

258 пунктның 2 графасында «ЯШЬЛЕК» яшьләр спорт үзәге» МББМУ» сүзләрен «ЯШЬЛЕК» яшьләр үзәге» МБУ» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтада:

1 пунктның 3, 6 һәм 8 графаларында «67928», «1068», «732» саннарын тиешенчә туры китереп, «67792», «1067», «730» саннарына алмаштырырга;

5 пунктның 2 графасында «Вертолеты-МИ» АҖ» сүзләрен «ВЕРТОЛЕТЫ-МИ» Казан фәнни-җитештерү предприятиесе АҖ» сүзләренә алмаштырырга;

67 пунктның 2 графасында «ДОМКОР» ҖЧҖ» сүзләрен «Махсуслаштырылган төзүче «ДОМКОР» ҖЧҖ» сүзләренә алмаштырырга;

76 пунктның 2 графасында «Таттелеком» ГАҖ» сүзләреннән соң «Яр Чаллы электр элемтәсе зональ узелы» сүзләрен өстәргә;

101 пунктның 2 графасында «Сөниев Әхнәф Галимулла улы» күмәк фермер хуҗалыгы» сүзләрен «Крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы Сөниев Әхнәф Галимулла улы» сүзләренә алмаштырырга;

120 пунктның 2 графасында «ТМС-групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәче компаниясе» сүзләрен «ТМС Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәче компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

121 пунктның 2 графасында «Консалтинг үзәге» ябык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «Консалтинг үзәге» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

145 пунктны көчен югалткан дип танырга;

209 пунктның 2 графасында «Кама Аланы» индустриаль паркы» ИК» ҖЧҖ сүзләрен «Нова Ролл-стрейч» ҖЧҖ» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кушымтада:

1 пунктның 11, 24 графаларында «389», «53» саннарын тиешенчә туры китереп, «390», «54» саннарына алмаштырырга;

13 пунктның 2 графасында «Сафьян» ҖЧҖ» сүзләрен «Сафьян» ААҖ» сүзләренә алмаштырырга;

33 пунктның 2 графасында «Ветераннар өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләрен «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

80 пунктның 2 графасында «Сөниев Әхнәф Галимулла улы» күмәк фермер хуҗалыгы» сүзләрен «Крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы Сөниев Әхнәф Галимулла улы» сүзләренә алмаштырырга;

116 пунктта:

11 графада «1» санын «2» санына алмаштырырга;

24 графасында «1» санын өстәргә;

117 пунктның 2 графасында «Әлмәт электромеханика заводы» ЯАҖ» сүзләрен «Әхмәмәт электромеханика заводы» ЯАҖ» сүзләренә алмаштырырга;

255 пунктның 2 графасында «28нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет балалар мәгариф учреждениесе» сүзләрен «28нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет балалар мәгариф учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт

казна учреждениесе, «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе директорларына, Кама Тамагы районы буенча Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге филиалы мөдиренә әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта әлеге карар кабул ителүгә бәйле рәвештә оешманың атамасы, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 2020 елга аларда билгеләнгән квоталар саны һәм (яки) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган эш урыннары саны үзгәрә торган эш бирүчеләргә язмача рәвештә җиткерергә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова